| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.03.2019 Казан ш. № 10-1/кс

2019-2023 елларга «Казан синтетик каучук заводы» ачык акционерлык җәмгыяте өчен су агызуга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Су агызуны гамәлгә ашыручы «Казан синтетик каучук заводы» ачык акционерлык җәмгыяте өчен, әлеге карарның 1 кушымтасына туры китереп, су агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Бу карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергәннән башлап 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булачак.

3. Су агызуны гамәлгә ашыручы «Казан синтетик каучук заводы» ачык акционерлык җәмгыяте өчен су агызуга, әлеге карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, 2019-2023 елларга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.

4. Су агызуны гамәлгә ашыручы «Казан синтетик каучук заводы» ачык акционерлык җәмгыятенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары

нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 22.02.2019 № 10-1/кс карарына 1 нче кушымта

Су агызуны гамәлгә ашыручы «Казан синтетик каучук заводы» ачык акционерлык җәмгыяте өчен су агызуга 2019-2023 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | |
| 1 | «Казан синтетик каучук заводы» ачык акционерлык җәмгыяте (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелә) | карар үз көченә кергән көннән башлап 30.06.2019 кадәр | 9,29 |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 9,29 |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 9,29 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 9,57 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 9,57 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 9,62 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 9,62 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 9,91 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 9,91 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 9,97 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 22.03.2019 № 10-1/кс карарына 2 нче кушымта

## Су агызуны гамәлгә ашыручы «Казан синтетик каучук заводы» ачык акционерлык җәмгыяте өчен су агызуга 2019-2023 елларга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Казан синтетик каучук заводы» ачык акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.2 | Су агызу | 2019 | 386,57 | 1 | – | - | 0,01 |
| | | 2020 | 398,17 | 1 | – | - | 0,01 |
| | | 2021 | 410,11 | 1 | – | - | 0,01 |
| | | 2022 | 422,42 | 1 | – | - | 0,01 |
| | | 2023 | 435,09 | 1 | – | - | 0,01 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге